**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19.06.2023 ел** **№ 762**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә белем бирүнең гомуми үстерелеш программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль өстәмә белем бирү учреждениеләренә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 июнендәге 584 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә карата таләпләрне билгеләргә хокуклы.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр расланды. 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карар белән югарыда күрсәтелгән таләпләргә үзгәрешләр кертелде.

Үзгәрешләрне исәпкә алып, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1.3.3 пунктчасына, түбәндәгеләрне бәян итеп, өченче абзацны өстәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формадагы гарызнамәнең һәрбер кырын тутыру процессында автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Шулай ук мөрәҗәгать итүчегә аның сайлавы буенча хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак, орган (оешма) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган машина укый ала торган форматта электрон документны бердәм порталны кулланып алу мөмкинлеге тәэмин ителә (алга таба - машина укый ала торган форматта электрон документ)».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы сайтына http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин